ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.06.2023 Балык Бистәсе штп. №187пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 23.05.2023 №157пи карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 23.05.2023 №157пи карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибе турындагы нигезләмәгә 3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«3.4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы тиешле муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларыннан түбәндәге чыгымнарны каплауны территориаль карамагына ярашлы рәвештә алырга:

- зиратларны карап тоту, зиратларны төзекләндерү һәм санитар чистарту эшләрен башкаруга;

- бюджеттан тыш фондлар һәм башка дәрәҗәләрдәге бюджетлар тарафыннан түләнми торган хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеген күрсәтүгә чыгымнар өлешен.»

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Д. Н. Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сатдинов